| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЗАЙ-КАРАТАЙСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ЗӘЙ-КАРАТАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

10 февраля 2021 ел № 1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2021 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» 2021 елның 28 гыйнварындагы карары нигезендә, «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы « Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен, 1, 2 нче кушымталар нигезендә, 6 424,98 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан республикасы Лениногорск муниципаль районы « Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында»гы 2020 елның 31 гыйнварындагы 4 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар 2021 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга (pravo.tatarstan.ru).

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль райны
«Зәй-Каратай авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы М.И.Идиятова

Кушымта №1

«Зәй-Каратай авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге Башкарма
комитеты карарына

«10» февраль 2021 ел № 1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча (туганнары булган) хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәясе 2021 елның 1 февраленнән

| Хезмәтләрнең атамасы | Хезмәтләрнең бәясе, сумн. |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2 433,68 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәдләрен) зиратка китерү | 1 216,84 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм җирләү) | 2 774,46 |
| Барлыгы | 6 424,98 |

Кушымта №2

«Зәй-Каратай авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты карарына

«10» февраль 2021 ел № 1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Зәй-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча (туганнары булмаган) хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәясе, 2021 елның 1 февраленнән

| Хезмәтләрнең атамасы | Хезмәтләрнең бәясе, сумн. |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Тәнне пакъләндерү | 605,28 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 1 828,40 |
| 4.Мәрхүмнең тәнен (җәсәден) зиратка китерү | 1 216,84 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм җирләү) | 2 774,46 |
| Барлыгы | 6 424,98 |